КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 16 декабрь г.Казань № 1353

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2025 елга кадәр Татарстан Республикасында сәламәтлек саклауны үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 1 июль, 461 нче карары белән расланган «2025 елга кадәр Татарстан Республикасында сәламәтлек саклауны үстерү» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2025 елга Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау системасын үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 1 июль, 461 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 15 май, 319 нчы; 2014 ел, 10 декабрь, 966 нчы; 2015 ел, 30 октябрь, 821 нче; 2016 ел, 12 апрель, 215 нче; 2016 ел, 22 сентябрь, 674 нче; 2017 ел, 13 гыйнвар, 4 нче; 2017 ел, 13 февраль, 80 нче; 2017 ел, 26 июнь, 429 нчы; 2017 ел, 4 октябрь, 760 нчы; 2018 ел, 30 июль, 612 нче; 2018 ел, 2 август, 625 нче; 2018 ел, 20 декабрь, 1194 нче; 2018 ел, 20 декабрь, 1197 нче; 2019 ел, 6 июнь, 472 нче; 2019 ел, 30 декабрь, 1239 нчы; 2020 ел, 8 сентябрь, 809 нчы; 2020 ел, 15 декабрь, 1138 нче; 2021 ел, 25 июнь, 497 нче; 2021 ел, 28 июнь, 513 нче; 2021 ел, 26 июль, 650 нче; 2021 ел, 1 декабрь, 1162 нче; 2021 ел, 22 декабрь, 1263 нче; 2022 ел, 16 май, 451 нче, 2022 ел, 31 май, 506 нчы, 2022 ел, 30 июнь, 615 нче, 2022 ел, 19 июль, 696 нчы, 2022 ел, 31 октябрь, 1155 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «2025 елга Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау системасын үстерү» дәүләт программасына (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

6 нчы ярдәмче программа. «Паллиатив ярдәм күрсәтү (шул исәптән балаларга)» («Татарстан Республикасында паллиатив медицина ярдәме күрсәтү системасын үстерү») яңа редакциядә бәян итәргә (карарга теркәлгән);

Программага 2 нче кушымтада:

«2 нче ярдәмче программа. «Махсуслаштырылган, югары технологияле, медицина ярдәмен, ашыгыч, шул исәптән махсуслаштырылган ашыгыч медицина ярдәмен, медицина эвакуациясен дә кертеп, күрсәтүне камилләштерү» бүлегендә (2а ярдәмче программасы. «Татарстан Республикасында йөрәк-кан тамырлары авыруларына каршы көрәш»; 2б ярәмче программасы. «Онкология авырулары белән көрәш»; 2 в ярдәмче программасы. «2019 – 2025 елларга Татарстан Республикасында трансплантологияне үстерү, югары технологияле медицина ярдәме күрсәтүне камилләштерү, дәвалауның яңа нәтиҗәле ысулларын үстерү») түбәндәге эчтәлекле 2.54 пункт өстәргә:

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «2.54. | Диспансер күзәтүендә торган хроник йөрәк-кан тамырлары авырулары (функциональ тайпылышлар, башка хәлләр) ачыкланган 18 яшьлек һәм өлкәнрәк затлар өлеше | процент | - | - | - | - | - | 77 | 80 | 80»; |

«6 нче ярдәмче программа. «Паллиатив ярдәм күрсәтү (шул исәптән балаларга)» («Татарстан Республикасында паллиатив медицина ярдәме күрсәтү системасын үстерү») бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| «6 нчы ярдәмче программа. «Паллиатив ярдәм күрсәтү (шул исәптән балаларга)» («Татарстан Республикасында паллиатив медицина ярдәме күрсәтү системасын үстерү») | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 6.1. | Паллиатив медицина ярдәменә мохтаҗ булган пациентларның гомуми санында паллиатив медицина ярдәме алган пациентлар өлеше, барлыгы | процент | 22 | 54 | 60 | 34,55 | 35 | 75 | 90 | 90 |
| 6.2. | Балаларга паллиатив ярдәм күрсәтү өчен паллиатив койкалар белән тәэмин ителеш | ятак / 10 мең балага | 0,33 | 0,33 | 0,35 | 0,37 | 0,37 | 0,41 | 0,43 | 0,43 |
| 6.3. | Өлкәннәргә паллиатив ярдәм күрсәтү өчен паллиатив койкалар белән тәэмин ителеш | ятак / 10 мең өлкән халык | 0,56 | 0,5 | 0,5 | 0,5 | 0,5 | 0,97 | 1,0 | 1,0 |
| 6.4. | Шәфкать туташлары тәрбиясенең паллиатив ятаклары белән тәэмин ителеш | ятак / 10 мең өлкән халык | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0,97 | 0,97 | 0,97 |
| 6.5. | Өлкәннәргә паллиатив медицина ярдәменең күчмә патронаж брига- | 100 мең өлкән кешегә берәмлек | - | - | - | 0,8 | 0,8 | 0,8 | 0,8 | 0,8 |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | далары тарафыннан тәэмин ителүе | | | | | | | | | |
| 6.6. | Балаларга паллиатив медицина ярдәменең күчмә патронаж бригадалары тарафыннан тәэмин ителүе | 100 мең балага берәмлек | - | - | - | 0,1 | 0,2 | 0,35 | 0,35 | 0,35 |
| 6.7. | Методик киңәшләр нигезендә исәпләнгән наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр булган дару препаратларына карата бирелгән ихтыяҗның күләме (авыртуны басуның 60 көнлек курсы): инвазив дару формаларында | процент | - | - | - | - | 80 | 82 | 83 | 85 |
| 6.8. | Методик киңәшләр нигезендә исәпләнгән наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр булган дару препаратларына карата бирелгән ихтыяҗның күләме (авыртуны басуның 60 көнлек курсы): кыска вакытлы тәэсирле инвазив булмаган дару формаларында | процент | - | - | - | 0 | 1 | 6 | 7 | 8 |
| 6.9. | Методик киңәшләр нигезендә исәпләнгән наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр булган дару препаратларына карата бирелгән ихтыяҗның күләме (авыртуны басуның 60 көнлек курсы): кыска вакытлы тәэсирле инвазив булмаган тәэсире озайтылган дару формаларында | процент | - | - | - | 58 | 59 | 60 | 61 | 62 |
| 6.10. | Наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр булган дару препаратларын сайлап алу вәкаләтләре наркотик матдәләрне һәм психотроп матдәләрне бүлү планы нигезендә игълан ителгән ихтыяҗлар кысаларында: инвазив дару формаларында | процент | - | - | - | 100 | 80 | 82 | 83 | 85 |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 6.11. | Наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр булган дару препаратларын сайлап алу вәкаләтләре наркотик матдәләрне һәм психотроп матдәләрне бүлү планы нигезендә игълан ителгән ихтыяҗлар кысаларында: инвазив булмаган кыска вакытлы тәэсирле дару формаларында | процент | - | - | - | 0 | 40 | 45 | 50 | 55 |
| 6.12. | Наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр булган дару препаратларын сайлап алу вәкаләтләре наркотик матдәләрне һәм психотроп матдәләрне бүлү планы нигезендә игълан ителгән ихтыяҗлар кысаларында: инвазив булмаган тәэсир итү вакыты озайтылган дару формаларында | процент | - | - | - | 50 | 55 | 62 | 63 | 65 |
| 6.13. | Медицина оешмаларында һәм структур бүлекчәләрдә паллиатив махсуслаштырылган медицина ярдәме күрсәтүче табиблар (биләгән вазыйфаларда физик затлар) саны | табиблар (физик затлар) саны | - | - | - | 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 6.14. | Паллиатив медицина ярдәме күрсәтү буенча дәваланган пациентларның гомуми санында стационар шартларда паллиатив медицина ярдәме күрсәтүче медицина оешмаларының структур бүлекчәләреннән социаль хезмәт күрсәтүне оешмаларына күчерелгән пациентлар өлеше | процент | - | 1 | 1 | 1,37 | 2 | 2 | 2 | 2 |
| 6.15. | Сәламәтлекне саклау өлкәсендә үз эшчәнлеген гамәлгә ашыручы коммерциячел булмаган оешмалар саны, шул исәптән Россия Федера- | берәмлек | - | - | - | 1 | 1 | 1 | 1 | 1». |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | циясе субъектлары бюджетларыннан субсидия рәвешендә, паллиатив медицина ярдәмен күрсәтүне оештыруны һәм аны алуга ярдәм итүне дә кертеп, паллиатив медицина ярдәменә мохтаҗ затларны медик-социаль озата баруны күзәтүче хезмәтләр күрсәтүгә дәүләт ярдәме чараларын алган коммерциячел булмаган оешмалар саны | | | | | | | | | |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин